КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1137

Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне тәэмин итү өчен хуҗалык җәмгыятьләре исемлеген раслау турында

«Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 2023 елның 20 июнендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләре, Татарстан Республикасы Рәисе белән килештерелгәннән соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан сайлап алу өчен билгеләнә, тәкъдим ителә торган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеген;

идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан сайлап алу өчен тәкъдим ителә торган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеген.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне тәэмин итү турында» 2021 ел, 2 апрель, 210 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне тәэмин итү турында» 2021 ел, 2 апрель, 210 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 17 апрель, 479 нчы карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 сентябрь, 1137 нче
карары белән расланды

Идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләре, Татарстан Республикасы Рәисе белән килештерелгәннән соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан сайлап алу өчен билгеләнә, тәкъдим ителә торган хуҗалык җәмгыятьләре
исемлеге

1. «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте.
2. «Органик синтез» Казан гавами акционерлык җәмгыяте.
3. «Камгэсэнергострой» акционерлык җәмгыяте.
4. «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте.
5. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте.
6. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 сентябрь, 1137 нче
карары белән расланды

Идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә
эш итүче вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан
сайлап алу өчен тәкъдим ителә торган хуҗалык җәмгыятьләре
исемлеге

1. «Казан оптика-механика заводы» акционерлык җәмгыяте.
2. «Казан вертолет заводы» акционерлык җәмгыяте.
3. «Түбән Кама техник углерод заводы» акционерлык җәмгыяте.
4. «Түбән Кама шин» гавами акционерлык җәмгыяте.
5. «Радиоприбор» акционерлык җәмгыяте.
6. «Содружество» акционерлык җәмгыяте.
7. «Инновацион индустриаль парк – «Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» технополисы» технопаркы» акционерлык җәмгыяте.